**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итү турында**

Бөек рус язучысы Л.Н. Толстойның Ватаныбыз һәм дөнья мәдәниятенә гаять зур өлеш кертүен исәпкә алып һәм 2028 елда аның тууына 200 ел тулу белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. 2028 елда Татарстан Республикасында Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итү уңаеннан чаралар уздырырга.

2. Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты төзергә.

3. Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 90 көн эчендә, Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты тәкъдимнәрен исәпкә алып, Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүне массакүләм мәгълүмат чараларында киң колачлы яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм җәмәгать берләшмәләренә 2028 елда Татарстан Республикасында Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашуны тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 19 ноябрь
№ 946

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның « 19 » ноябрендәге
946 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты турында**
**нигезләмә**

1. Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) Татарстан Республикасында Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру, шулай ук әлеге чараларны уздыруда катнаша торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатларында төзелә.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планына (алга таба – Чаралар планы) тәкъдимнәр эшләү;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Чаралар планын үтәү белән бәйле бурычларны хәл итү буенча эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

в) Чаралар планын үтәү мәсьәләләрен карап тикшерү һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр эшләү.

4. Оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны үтәү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча

территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрдән Оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) Оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлы эш төркемнәре төзергә;

в) үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен чакырырга.

5. Оештыру комитеты составын Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

6. Оештыру комитеты составына аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша торган Оештыру комитеты рәисе, Оештыру комитеты рәисе урынбасарлары, Оештыру комитеты секретаре һәм Оештыру комитетының әгъзалары керә.

7. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен, әмма кимендә елга бер тапкыр уздырыла.

8. Оештыру комитеты утырышларын Оештыру комитеты рәисе яисә аның йөкләве буенча Оештыру комитеты рәисе урынбасарларының берсе алып бара.

9. Утырышларның көн тәртибен, аларны уздыру урынын һәм тәртибен Оештыру комитеты рәисе билгели.

10. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда Оештыру комитеты әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

11. Оештыру комитеты карарлары аның утырышында катнашучы Оештыру комитеты әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Оештыру комитеты әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, аның фикере Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

12. Оештыру комитеты утырышында мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә Оештыру комитеты утырышында рәислек итүче кул куя.

13. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар кызыксынган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә һәм башка кызыксынган затларга җиткерелә.

14. Оештыру комитеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектлары әзерләнергә мөмкин.

15. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар белән һәм мәгълүмати тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тормышка ашыра.

___________

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «19» ноябрендәге
946 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Л.Н. Толстойның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы рус теле комиссиясе рәисе, оештыру комитеты рәисе |
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Низамова Ләйсән Габделхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, оештыру комитеты секретаре |
| Александровская Ирина Алексеевна | «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы рус теле комиссиясе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Алешков Николай Петрович | «Аргамак. Татарстан» әдәби журналы баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Афанасьев Михаил Павлович | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Бушканец Лия Ефимовна | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – Л.Н. Толстой музее мөдире, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Лев Толстой исемендәге рус филологиясе һәм мәдәнияте югары мәктәбенең рус әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улы | «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы |
| Горнышева Айгөл Алмас кызы | «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы | «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» региональ җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Җамалетдинов<br>Рәдиф Рифкать улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Иванов<br>Дмитрий Алексеевич | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Кадыйров<br>Азат Рифгать улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миңнеханов<br>Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президенты |
| Мөбарәкшина<br>Гүзәл Мөхәррәм кызы | «Т.Г. Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасының дәүләт автоном мәдәният учреждениесе директоры |
| Мөхәрләмов<br>Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Руденко<br>Гөлзадә Рәкыйп кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы генераль директоры |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Силкин<br>Артем Николаевич | Татарстан Республикасының «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры |
| Скучаева<br>Светлана Анатольевна | «Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәбият музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры |
| Тимерҗанова<br>Мәдинә Фатыйх кызы | «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры |
| Фәйзрахманов<br>Айрат Шамил улы | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директоры вазыйфаларын башкаручы |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шаталов<br>Вячеслав Владимирович | Татарстан Республикасының «Мәдәниятләр һәм багланышлар үзәге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы директоры, «Татарстан Республикасының рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасының яшьләр бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |